| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**28.01.2020** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 113** |

Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы, «Балигъ булмаганнарга составында тәмәке булмаган никотинлы продукция сатуны, никотин китертүнең электрон системаларын тыю һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 25 декабрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә, административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген расларга.
2. «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 07 февралендәге 278 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкченең беренче урынбасары А.В.Старостин